**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы №146 18.12.2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 12 августындагы 103 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2015 елның 16 ноябрендәге 16 номерлы, 2016 елның 13 декабрендәге 45 номерлы, 2019 елның 23 апрелендәге 134 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 160 номерлы, 2021 елның 12 мартындагы 21 номерлы, 2021 елның 12 октябрендәге 39 номерлы, 2023 елның 01 февралендәге 81 номерлы, 2023 елның 21 сентябрендәге 99 номерлы, 2024 16 январендагы 111 номерлы, 2024 елның 24 апрелендәге 123 номерлы, 2024 елның 28 ноябрендәге 142 номерлы карарлар редакциясендә )

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2014 елның елның 12 августындагы 103 номерлы номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (16.11.2015 №16, 13.12.2016 №45, 23.04.2019 №134, 11.02.2020 №160, 12.03.2021 №21,

12.10.2021 №39, 01.02.2023 №81, 21.09.2023 №99, 16.01.2024 №111, 24.04.2024 №123, 28.11.2024 №142 карарлар редакциясендә түбәндәге эчтәлекле 10.2 бүлек өстәп, үзгәреш кертергә:

"10.2 бүлек. Анкета тапшыру, анкетадагы белешмәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итү һәм белешмәләрне тикшерү

1. Гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетадагы белешмәләргә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкетаның формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләр исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы (эш бирүче) вәкиле яисә ул вәкаләт биргән зат карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, гарызнамәләр җибәрү юлы белән муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гавами хакимият органнары һәм тиешле мәгълүматка ия оешмалар әлеге сорауны алган көннән бер айдан да соңга калмыйча сорала торган мәгълүматны бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә” түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Й.Әхмәтшин